# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Уен бизнесына салым ставкалары турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 16 февралендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон белән Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә уен бизнесы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар өчен уен бизнесына салым ставкалары билгеләнә.

2 статья. **Уен бизнесына салым ставкалары**

Уен бизнесына салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:
1) тотализаторның бер процессинг үзәге өчен – 125 000 сум;
2) букмекерлык конторасының бер процессинг үзәге өчен – 125 000 сум;
3) тотализаторның ставкалар кабул итү буенча бер пункты өчен – 7000 сум;
4) букмекерлык конторасының ставкалар кабул итү буенча бер пункты өчен – 7000 сум.

3 статья. **Татарстан Республикасының аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:
1) "Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында" 2003 елның 23 сентябрендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 9 (II өлеш);
2) "Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2005 елның

23 ноябрендәге 112-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11).

4 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән бер ай үткәч, әмма уен бизнесына салым буенча чираттагы салым чорының беренче числосыннан иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2012 елның 24 феврале
№ 11-ТРЗ